КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 сентябрь г.Казань № 865

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллыгына әсәрләр иҗат итү буенча проектларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы барлыкка килү тарихына бәйле тарихый вакыйгаларның әһәмиятен чагылдыра торган әдәбият һәм сәнгать әсәрләре фондын булдыру максатларында һәм Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы барлыкка килүенең 100 еллыгын бәйрәм итү алдыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллыгына әсәрләр иҗат итү буенча проектларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын булдыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә һәм аларны түбәндәге номинацияләр буенча гамәлгә куярга:

«Әдәбият»;

«Музыкаль сәнгать»;

«Сынлы сәнгать»;

«Балалар өчен төрле жанрлардагы сәнгать».

2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллыгына әсәрләр иҗат итү буенча проектларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 21 сентябрь, 865 нче
карары белән расланды

# Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллыгына әсәрләр иҗат итү буенча проектларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип 2019 елда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллыгына әсәрләр иҗат итү буенча проектларны тормышка ашыру өчен мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар (алга таба – грантлар) бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Грантлар бирү «2019 елга һәм 2020 – 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Грантлар конкурс нигезендә бирелә.

1.4. Грантлар конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган проектларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү максатларында түбәндәге номинацияләр буенча бирелә:

кече формадагы әдәби әсәрләр (проза, поэзия) – һәрберсе 100 мең сум күләмендә 20 грант;

зур формадагы әдәби әсәрләр (проза, поэзия) – һәрберсе 50 мең сум күләмендә 6 грант;

камера музыкасы жанрларындагы кече формадагы музыкаль әсәрләр – һәрберсе 50 мең сум күләмендә 5 грант;

вокал, хор музыкасы жанрларындагы кече формадагы музыкаль әсәрләр – һәрберсе 50 мең сум күләмендә 5 грант;

симфония музыкасы жанрларындагы кече формадагы музыкаль әсәрләр – һәрберсе 100 мең сум күләмендә 5 грант;

зур формадагы музыкаль әсәрләр, шул исәптән циклик әсәрләр – һәрберсе 200 мең сум күләмендә 4 грант;

музыкаль-театраль жанрлар – һәрберсе 600 мең сум күләмендә 2 грант;

скульптура – һәрберсе 500 мең сум күләмендә 4 грант;

рәсем сәнгате – һәрберсе 500 мең сум күләмендә 4 грант;

декоратив-гамәли сәнгать – һәрберсе 250 мең сум күләмендә 4 грант;

балалар өчен әдәбият – һәрберсе 50 мең сум күләмендә 12 грант;

балалар өчен музыкаль сәнгать – һәрберсе 70 мең сум күләмендә 20 грант.

1.5. Бу Тәртипне куллану максатларында, түбәндәге терминнар кулланыла:

грантка дәгъва итүчеләр – Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә эшчәнлек алып баручы 18 яшьтән өлкән Россия Федерациясе гражданнары;

грант алучы – конкурста җиңүче дип танылган һәм вәкаләтле орган белән грант бирү турында килешү төзегән грантка дәгъва итүче.

1.6. Грантка дәгъва итүче түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

грантка дәгъва итүче тарафыннан агымдагы финанс елында бу Тәртип белән билгеләнгән максатлар өчен башка хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алынмаган;

грантка дәгъва итүченең Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары, Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

дәгъва итүченең Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмаган.

1.7. Грантлар алу хокукына конкурс (алга таба – конкурс) үткәрүне оештыру Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган бу Тәртип кысаларында:

конкурс, конкурста катнашучыларга карата таләпләр һәм аның йомгаклары турындагы мәгълүматны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастыруны тәэмин итә;

конкурста катнашуга заявкалар (алга таба – заявкалар) әзерләү мәсьәләләре буенча консультация бирүне оештыра;

заявкалар һәм аларга теркәлгән документларны кабул итүне һәм теркәүне оештыра;

бирелгән заявкаларның саклануын тәэмин итә;

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллыгына әсәрләр иҗат итү буенча проектларга Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын конкурс нигезендә бирү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Комиссия карары беркетмәсенә имза куйганнан көннән өч көн эчендә Комиссия карарын боерык белән раслый;

конкурсның грант алучылары белән грантлар бирү турында килешү төзи;

бирелгән грантларның максатчан файдаланышын тикшерүдә тота.

## 2. Грант бирүнең максатлары

2.1. Грант бирүнең максатлары – түбәндәгеләр:

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллыгын бәйрәм итү алдыннан тарихый вакыйгаларның әһәмиятен чагылдыра торган әсәрләр иҗат итү буенча проектларны ачыклау һәм тарату;

дәүләт хакимияте органнары белән мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренең хәзерге заман әдәбиятын, музыка һәм рәсем сәнгатен яңа әсәрләр белән баету мәсьәләләрен хәл итүдә үзара хезмәттәшлеге формаларын камилләштерү;

Татарстан Республикасы халыкларының рухи-әхлакый кыйммәтләрен ныгыту һәм мәдәниятен үстерү өчен шартлар тудыру.

## 3. Грант бирүнең шартлары

3.1. Грант аны алучыга түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

грант Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллыгын бәйрәм итү алдыннан тарихый вакыйгаларның әһәмиятен чагылдыра торган әсәрләр иҗат итү буенча проектны тормышка ашыруга (грант алучыга авторлык бүләкләвен түләүне кертеп) юнәлдерелә;

грант алучы вәкаләтле органга әзер сәнгать әсәрен, шулай ук килешү һәм кабул итү-тапшыру акты нигезендә, Россия Федерациясе Граждан кодексына таянып, сәнгать әсәрен файдалануга аерым хокук бирүне вәгъдә итә.

## 4. Заявкаларны кабул итү шартлары һәм бирү тәртибе

4.1. Вәкаләтле орган конкурс үткәрү турында карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән өч көн эчендә үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында конкурс үткәрү турында белдерү урнаштыра.

4.2. Заявкаларны кабул итү конкурс үткәрү турындагы белдерүне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырган көннән 60 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

4.3. Конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен грантка дәгъва итүчеләр вәкаләтле органга түбәндәгеләрне кертә:

бу Тәртип белән билгеләнгән форма буенча грантка дәгъва итү өчен конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга заявка (алга таба – заявка), шул исәптән анда түбәндәгеләр турында мәгълүмат бирелә:

проект номинациянең техник биременә туры килү;

әсәр иҗат итү буенча проект элегрәк басылып чыкмау (яңгырамау, киң тамашачыга тәкъдим ителмәү);

әсәр иҗат итү буенча проектның башка финанслау чыганаклары булмау, шул исәптән гонорар рәвешендә финансланмау;

паспортның яки шәхесне таныклый торган башка документ күчермәләре;

салым түләүченең тәңгәлләштерелгән номеры, иминият таныклыгы күчермәләре;

тәкъдим ителгән проектның кыскача аннотациясе (текст MS Word (.doc яки .docx) форматында Times New Roman стандартлы шрифты (14 пт.) белән);

тапшырылган документларның исемлеге.

Грантка дәгъва итүче бер зат бер генә гариза бирергә, аның составында конкурста катнашу өчен бер генә эш тәкъдим итәргә мөмкин.

4.4. Һәр номинация өчен техник бирем вәкаләтле органның боерыгы белән карар басылып чыккан көннән җиде көн эчендә раслана.

4.5. Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар брошюралаштырылган булырга тиеш. Барлык документлар төгәл бастылган булырга тиеш. Чистартып язулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

4.6. Заявка әзерләү буенча барлык чыгымнарны грантка дәгъва итүче үзе күтәрә.

4.7. Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар кәгазь яки электрон чыганакта 420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33 нче йорт адресы буенча 113 нче кабинетка тапшырыла. Телефон: (843) 264-73-91.

4.8. Заявканы кабул иткәндә вәкаләтле орган аны кабул иткән көнне заявкаларны исәпкә алу журналында терки.

Заявка вәкаләтле органга почта аша кергәндә, ул бер көн эчендә заявкаларны исәпкә алу журналында теркәлә.

4.9. Заявкаларны кабул итү вакыты тәмамланганнан соң вәкаләтле органга кергән (шул исәптән почта аша) заявка теркәүгә алынмый, һәм грантка дәгъва итүче конкурста катнаша алмый.

4.10. Вәкаләтле орган гаризаларны кабул итү тәмамланганнан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә барлык кергән заявкаларны Комиссиягә тапшыра.

4.11. Вәкаләтле орган тарафыннан заявкалар тапшырылган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә тапшырылган заявкалар Комиссия тарафыннан бу Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә карап тикшерелә.

4.12. Грантка дәгъва итүчегә конкурс нигезендә сайлап алуда катнашудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

дәгъва итүченең бу Тәртип таләпләренә туры килмәве;

заявкада бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы яки аның билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

4.13. Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән грантка дәгъва итүчеләр исемлеге һәм конкурста катнашырга рөхсәт ителмәгән грантка дәгъва итүчеләр исемлеге Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.14. Комиссия утырышы беркетмәсен раслаганнан соң, конкурста катнашучылар исемлеге, шулай ук конкурста катнашырга рөхсәт ителмәгән грантка дәгъва итүчеләр исемлеге эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

4.15. Конкурста катнашучылар исемлеге расланганнан соң, Комиссия заявканы һәм аларга теркәлгән документларны эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Комиссия тарафыннан расланган экспертлар исемлегенә кертелгән экспертларның карап тикшерүенә тапшыра.

4.16. Вәкаләтле органга кергән заявка кире кайтарылмый.

4.17. Һәр проект ике эксперт тарафыннан карап тикшерелә. Экспертлар проектларны бу Тәртипнең 4.18 нче пункты белән билгеләнгән критерийлар нигезендә бәяли. Заявканы карап тикшергән экспертларның бәяләүләре 25 һәм аннан да күбрәк баллга аерылса, проект Комиссия тарафыннан билгеләнгән өченче эксперт тарафыннан карап тикшерелә.

4.18. Заявкаларны бәяләү түбәндәге критерийлар буенча 10 баллы (0 дән 10 га кадәр) шкала буенча башкарыла:

проектның сәнгати кыйммәте һәм әһәмияте (0 – 10 балл);

конкурс тематикасына туры килү, ягъни проект Татарстан Республикасы тарихыннан булган вакыйгаларны, Татарстанны данлаган һәм татар халкының дәүләтчелеге һәм мәдәнияте үсешенә зур йогынты ясаган күренекле шәхесләрнең өлешен чагылдырырга тиеш (0 – 10 балл);

милли сәнгать традицияләренә таяну (0 – 10 балл);

проектның гражданлык-патриотик характеры (0 – 10 балл);

Татарстан Республикасы халкының рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләрен ныгытуда социаль-мәдәни нәтиҗә (0 – 10 балл).

4.19. Комиссия заявкаларны экспертларга тапшырган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә экспертлар заявкаларны һәм аларга теркәлгән документларны карап тикшерә һәм эксперт бәяләмәләрен Комиссиягә тапшыра.

4.20. Заявкаларга эксперт бәяләмәсен бирү барышында экспертка билгеле булган мәгълүмат конфиденциаль булып тора һәм фаш ителмәскә тиеш.

4.21. Комиссия эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә грантка дәгъва итүче тарафыннан күрсәтелгән номинациядә җыелган баллар саны буенча җиңүчеләрне билгели. Заявканың гомуми баллары саны бу Тәртипнең 4.18 нче пунктында күрсәтелгән критерийлар буенча җыелган балларны гомумиләштерү юлы белән билгеләнә. Заявкасы бирелгән номинациядә иң күп балл җыйган грантка дәгъва итүче зат җиңүче дип танproblem.

4.22. Проектлар бер үк санда балл җыйган очракта, заявкасы алданрак бирелгән проект җиңүче дип танылa.

4.23. Бирелгән номинациядә 25тән дә кимрәк балл җыйган проект җиңүче дип танылa алмый.

4.24. Конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары (грант алучыларның бирелә торган грант күләмнәре күрсәтелгән һәм расланган исемлеге) аларны раслаган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтка урнаштырыла.

## 5. Грантка дәгъва итүгә конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибе

5.1. Грантка дәгъва итүгә конкурс нигезендә сайлап алу Комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.2. Комиссия вәкаләтле орган вәкилләреннән, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге экспертлардан, җәмәгатьчелек вәкилләреннән төзелә һәм вәкаләтле орган боерыгы белән раслана, аның составында Комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм 11 кешедән торган Комиссия әгъзалары була.

5.4. Комиссия эше аның утырышларында гамәлгә ашырыла. Әгәр дә утырышта Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

5.5. Комиссия карарлары аның утырышында катнашкан әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә һәм Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссия утырышында катнашкан әгъзалар имза куя һәм аларны Комиссия утырышы үткәрелгән көннән өч көн эчендә Комиссия рәисе раслый. Комиссия әгъзасының аерым фикере булган очракта, ул шулай ук Комиссия утырышы беркетмәсенә кертелә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Комиссия утырышының беркетмәсе вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, беркетмә расланган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча, ачык рәвештә урнаштырыла.

5.6. Комиссия әгъзасының, шулай ук Комиссия әгъзасына йогынты ясарга сәләтле затның кызыксынуы булган аерым бер грантка дәгъва итүченең заявкасы тапшырылган очракта, Комиссия әгъзасы Комиссия эшендә катнашмый.

5.7. Комиссиянең оештыру-техник эшчәнлеген яраштыру, утырышларын әзерләү һәм документларын алып бару өчен Комиссия рәисе вәкаләтле органның тавыш бирү хокукы булмаган хезмәткәрләре арасыннан Комиссия сәркатибен билгели.

## 6. Грант бирү тәртибе

6.1. Вәкаләтле орган грант алучылар исемлеген раслаган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә алар белән үзе раслый торган форма буенча грант бирү турында килешүләр төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр күздә тотыла:

грант алучыга грант бирү тәртибе, күләме, вакытлары һәм формасы, финанслар белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисап документларын тапшыру;

максатчан билгеләнеше, аны күчерү тәртибе һәм вакытлары, аннан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе һәм вакытлары, бу Тәртиптә күрсәтелгән очракларда, грантны кире кайтару тәртибе, грантка дәгъва итүченең вәкаләтле орган, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан грант бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы, килешү шартларын бозган өчен җаваплылык.

Вәкаләтле орган тарафыннан грант күчерү килешү яклары имза куйган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә грантка дәгъва итүченең Россия кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 7. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Грант алучылар вәкаләтле органга аның тарафыннан расланган форма буенча һәм килешү белән күздә тотылган тәртиптә грантны файдалану турында хи-

сап тапшыра, шулай ук вәкаләтле органга тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап бирә.

Гранттан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану өчен җаваплылык грант алучыга йөкләнә.

7.2. Грантлар вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

грант алучы тарафыннан баш эш итүче һәм вәкаләтле дәүләт финанс тикшерүе органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган грант бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлмәгәндә;

грант алучылар тарафыннан дөрес булмаган мәгълүматлар бирелгәндә.

7.3. Грантны кире кайтару турындагы хәбәрнамә кире кайтару өчен бу Тәртипнең 7.2 нче пунктында күрсәтелгән нигезләр ачыкланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә грант алучыга язма рәвештә җибәрелә.

7.4. Грант алучы тарафыннан грантны кире кайтару өчен билгеләнгән вакыт бозылганда, вәкаләтле орган бу Тәртипнең 7.2 нче пунктында күрсәтелгән вакыт тәмамланган көннән 30 көн эчендә грантны Татарстан Республикасы бюджетына законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

7.5. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы законнар нигезендә грант алучылар тарафыннан грантлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

___

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының 100 еллыгына әсәрләр иҗат итү буенча проектларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының
100 еллыгына әсәрләр иҗат итү буенча проектларны тормышка ашыруга
Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын алуга конкурста катнашу өчен
заявка

1. Ф.Ис.Ат.ис.:______________________________________________________
Тел.:____________________________________________________________
Адресы:__________________________________________________________
Эл.адресы:________________________________________________________
2. Эш урыны, вазыйфасы:__________________________________________
3. Татарстан Республикасының, Россия Федерациясенең иҗат берлегендә әгъзалыгы турында мәгълүмат:_____________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
4. Проект турында мәгълүмат:_______________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
Исеме:_____________________________________________
Номинация:_________________________________________________
5. Сез кайчан да булса дәүләт гранты яки муниципаль грант, әдәби премия алганыгыз булдымы? Җавап уңай булса, әсәрнең (җыентыкның) елын, исемен, проектның исемен һәм грант (премия) суммасын күрсәтегез: ________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
6. Иҗади проектның (әсәрнең) кыскача тасвирламасы:____________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

*(әсәрнең төп эчтәлеген кыскача бәян итү: темасы, идеясе, синопсисы (прозаик әсәрләр өчен) һәм шигъри һәм лиро-эпик әсәрләр өчен якынча планы).*

7. Әсәр темасының һәм идеясенең актуальлеге (яшьләргә әхлакый, патриотик тәрбия бирүгә өлеше, тарихны чагылдыру тирәнлеге, татар халкының милли гореф-гадәтләрен, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының барлыкка килү тарихын һәм Татарстан Республикасының икътисады, мәдәнияте, социаль тормышы үсешендә заманча казанышларны һәм перспективаларны, спорт өлкәсендәге казанышларны һ.б.): ____________________________________________

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

8. Проектны тормышка ашыру вакытлары:______________________________

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

9. Проект (әсәр иҗат итү) тормышка ашырыла торган вакыт эчендәге эшнең һәр этабы өчен планы (мәгълүмат бирү формасы экспертка бирелгән эш планының тормышка ашырылуын һәм аны үтәмәү куркынычын бәяләргә мөмкинлек бирергә тиеш): ____________________________________________________________

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

10. Грантка дәгъва итүченең иҗади казанышларын, авторның әсәрләр исемлеген, шулай ук аларны бастырып чыгару урынын һәм датасын күрсәтеп, кыскача тасвирлау:_____________________________________________________

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

11. Түләү реквизитлары:________________________________________
12. Банк исеме :_________________________________________
13. Адресы:_______________________________________________________
14. Исәп-хисап счеты:_____________________________________________

Гаризада бирелгән барлык мәгълүмат, шулай ук өстәмә материаллар ышанычлы һәм дөрес дип белдерәм һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының миннән һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарыннан тапшырылган мәгълүматларны ачыклый торган мәгълүмат соратып алуга хокукын раслыйм.

Ф.Ис.Ат.ис.__________________________ Имзасы ________________________

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә каршы килмим.

Ф.Ис.Ат.ис.___________________________ Имзасы_________________________

Датасы _____________________________